ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Карата авыл җирлеге

башкарма комитеты
района

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Старохурадинского сельского
поселения
Алькеевского муниципального

Адресы: 422898, РТ, Сиктерме-Хузангай авылы, Мектеп ур., 15 Тел/факс: (84346) 73-4-03
Адрес: 422898, РТ, с. Сиктерме-Хузангаево, ул. Школьная, 15 тел/факс: ( 84346) 73-4-03

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**2021 елның 7 июне** **Иске Карата авылы** **21 №**

Иске Карата авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 13 апрелендәге «2021 - 2024 елларда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 7 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары тарафыннан эшмәкәрлек эшчәнлеген алып бару өчен уңайлы икътисадый мохит булдыру максатларында Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Иске Карата авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 13 апрелендәге 7 номер белән расланган «2021 - 2024 елларда Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районы Иске Карата авыл җирлегендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» муниципаль программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. Программа паспортында «Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» графасында «Әлки муниципаль районы халкын эш белән тәэмин итү программасы. Кредит акчалары һәм эшмәкәрләрнең үз акчалары. Җирле бюджет чараларын финанслау» сүзләрен алмаштырырга:
«Җирле бюджет акчалары хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:

(мең сумнарда)

| Ел | Җирле бюджет акчалары |
|---|---|
| 2021 | 1 |
| 2022 | 1 |
| 2023 | 1 |
| 2024 | 1 |
| Барлыгы | 4» |

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 5 нче бүлек өстәргә:

«5. Программаны финанслау:

Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына методик, консультацион-мәгълүмати ярдәм күрсәтү, шулай ук җирле бюджет акчалары исәбеннән финанс, мәгълүмати һәм башка ярдәм алу механизмнары турында мәгълүмат бирү максатларында түбәндәге чаралар финанслана:

(мең сумнарда)

| Чара исеме | Акча күләме | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 2021 ел | 2022 ел | 2023 ел | 2024 ел |
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен методик кулланмалар, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | 1 | 1 | 1»; |

1.3. Кушымта таблицасына түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен методик кулланмалар, мәгълүмати буклетлар, брошюралар, плакатлар, белешмәлекләр эшләү | 1 | Авыл җирлеге Башкарма комитеты | 2021-2024 | Үткәрелгән чаралар саны, бер. | 1 | 1 | 1 | 1 |

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми http:pravo.tatarstan.ru порталында бастырып чыгарырга.

Иске Карата авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе: Кузнецов Н.В.